**5 нче сыйныф**

**Татар әдәбиятыннан тест**

**Мәсәлләр. Габдулла Тукай һәм Әхмәт Исхак мәсәлләре**

**1.Нәрсә ул мәсәл?**

а) аллегорик характердагы, ягъни читләтеп әйтүгә, кимиягә корылган, гыйбрәтле, акыл-әхлак өйрәтүле кечкенә хикәя;

ә) мактау эчтәлегендәге лирик жанр;

б) лиро-эпик поэзиянең хикәяләү характерындагы бер төре.

**2.Мәсәлдә бирелгән персонажлар нәрсәне белдерә?**

а) төлке — хәйләкәрлекне, бүре — ерткычлыкны, ишәк — наданлыкны, куян — куркаклыкны, сандугач — матурлыкны;

ә) кырмыска — тырышлыкны, арыслан — көчне, бүре – наданлыкны;

б) куян — көчне, төлке — ерткычлыкны.

**3.Урта гасырларда иҗат иткән язучыны билгеләгез.**

а) Мәхмүд Болгари;

ә) Иван Крылов;

б) Габдулла Тукай.

**4.XIX гасырда иҗат иткән мәсәлчене күрсәтегез.**

а) Каюм Насыйри;

ә) Габдулла Тукай;

б) Мөхәммәдьяр.

**5. XX гасыр мәсәлчеләре кемнәр?**

а) Мәхмүд Болгари, Мөхәммәдьяр, Һибәтулла Салихов;

ә) Каюм Насыйри, Габдулла Тукай, Мәҗит Гафури;

б) Мәҗит Гафури, Әхмәт Исхак, Габдулла Шамуков.

**6. Габдулла Тукай һәм Әхмәт Исхакның бер ук темага язылган мәсәлләре ничек атала?**

а) «Бакчада йөзем җимеше»;

ә) «Төлке һәм йөзем җимеше», «Төлке һәм виноград»;

б) «Пешмәгән виноград».

**7. Бирелгән мәсәл юллары кемнеке?**

*«Әле пешмәгәннәр, җитешмәгәннәр,*

*Эчең бозылуы бар, мондыйларны ашап».*

а) Габдулла Тукайныкы;

ә) Әхмәт Исхакныкы;

б) Иван Крыловныкы.

**8. Виноградның килосы элек ничә сум торган?**

а) утыз сум;

ә) утыз биш сум;

б) кырык сум.

**9. Йөзем җимешен алу өчен, Әхмәт Исхак Төлкесе кая бара?**

а) бакчага;

ә) базарга;

б) басуга.

**10. Төлке виноградларны ни өчен алмый?**

а) акчасы җитми;

ә) ашыйсы килми;

б) буе җитми.

**Ачкыч**

1. А
2. А
3. А
4. А
5. Б
6. Ә
7. Ә
8. А
9. Ә
10. А

# Бәяләү

**9-10 балл – “5”ле**

**7-8 балл – “4”ле**

**5-6 балл – “3”ле**